ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2022 Олы Кайбыч ав. №251

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Халыкның уңайлы тормыш шартларына хокукларын, җир кишәрлекләренә хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча 2022 елның 1 июлендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында гавами тыңлаулар үткәрергә.
3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проектында һәм ызанлау проектында булган материаллар (текст һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча танышырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проектында һәм межалау проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:
Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Бушанчы-Кече Урсак» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты материалларын урнаштырырга;

-әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга;
гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р. Сәлаховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров